ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл
җирлеге Советы

422756, ТР Әтнә муниципаль районы,
Олы Мәңгәр авылы, Совет урамы, 8
тел. 34-6-25

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
Совет Большеменгерского
сельского поселения
Атнинского муниципального района

422756, РТ, Атнинский муниципальный район,
село Большой Менгер, улица Советская, 8
тел. 34-6-25

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы**

**КАРАР**

«28» июнь 2019 ел. № 98

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының «Олы Мәңгәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 22 октябрендәге 59 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон (соңгы үзгәрешләр белән) нигезендә, Әтнә районы прокуратурасының 2019 елның 21 мартындагы 02.01.15-19 номерлы тәкъдимен өйрәнеп һәм карап, предприятиеләрнең, оешмаларның, учреждениеләрнең, вазыйфаи затларның һәм гражданнарның санитар һәм экологик торышлары өчен җаваплылыгын арттыруны һәм тикшереп торуны көчәйтү һәм авыл җирлеге территориясендә чисталык һәм тәртип саклау максатыннан Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы **КАРАР ИТТЕ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 октябрендәге 59 номерлы карары нигезендә расланган «Олы Мәңгәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» гы карарына 1 нче номерлы кушымта нигезендә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертергә.
2. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында, Әтнә муниципаль районының Интернет челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб–адресы буенча һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында: pravo.tatarstan.ru веб–адресы буенча урнаштырырга.
3. Әлеге карар рәсми халыкка игълан ителгәннән соң үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге башлыгы В.В.Хисматуллин

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2019 елның
28 июнендәге 96 номерлы карарына
1 нче номерлы кушымта

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының «Олы Мәңгәр авыл җирлеге муниципаль берәмлеге территориясендә төзекләндерү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 22 октяберендәге 59 номерлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»**

1. Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2017 елның 22 октябрендәге 59 нчы номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. «Территорияләрне төзекләндерү, карап тоту һәм җыештыру буенча гомуми таләпләре» 3 нче өлешендә 3.3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.3. Физик затлар, шәхси эшмәкәрләр, юридик затлар барлык җирлек территориясендә урнашкан төзекләндерү объектларында һәм билгеләнгән территорияләрдә чисталык, тәртип сакларга һәм тиешле тәртиптә тоту өчен чаралар күрергә тиеш. Сосновская борщевигын җир алар милке, файдалануда яки кулланышта булган очракта мөстәкыйль рәвештә үз акчасына юк итү буенча чаралар үткәрелергә тиеш. (Сосновская борщевигын бетерү буенча чаралар аны бутонизацияләүгә һәм чәчәк ата башлаганчы башкарылырга тиеш)».

1.2. "Территорияләрне төзекләндерү, карап тоту һәм җыештыру буенча гомуми таләпләр» 3 нче өлешендә 3.6 пунктын 3.6.1 пунктчасы белән түбәндәге эчтәлектә тулыландырырга.:

«3.6.1. Физик һәм юридик затлар чүп үләннәрен һәм куак үсемлекләрен, барыннан да элек, гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч тудыручы үсемлекләрне юкка чыгару буенча эшләр башкарырга тиеш. (шул исәптән Сосновская борщевигы).
үз милкендәге, файдалануда яки кулланышта булган җир кишәрлекләрендә гражданнарның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч тудыра торган үсемлекләр үсә торган юридик затларга (шәхси эшмәкәрләргә) һәм физик затларга күрсәтелгән эшләрне үтәмәгән өчен җаваплылык йөкләнә.»

1.3. «Индивидуаль торак йортларны карап тоту һәм территорияне төзекләндерү» 4 нче өлешендә 4.28 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10 нчы пунктча өстәргә:

«10) Сосновская борщевигын җир алар милке, файдалануда яки кулланышта булган очракта мөстәкыйль рәвештә үз акчасына юк итү буенча чаралар үткәрелергә тиеш. (Сосновская борщевигын бетерү буенча чаралар аны бутонизацияләүгә һәм чәчәк ата башлаганчы башкарылырга тиеш)».